| СОВЕТ ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** Урман Асты Шонталасы ав. **КАРАР**

10.08.2023 № 40

Җирле салымнар суммасы буенча
бурычларны түләтүгә өметсез дип
тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүче гражданның-физик затның стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән аль п өч еллык срок тәмамлану.

2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советының 04.07.2017ел №51 «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимка һәм бурычларны түләтүгә һәм юкка чыгаруга ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында» карары.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәмУрман Асты Шонталасы авыл җирлегенең мәглүмати стендында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет Рәисе** **А.Ә.Җиһаншин**

СОВЕТ ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОЕ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ОГРН 1021605753641
ИНН 1605000819